РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12,
г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 29 апреле № 32

Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1 пунктта «яки Түбән Кама шәһәре Мэры» сүзләрен «, Түбән Кама шәһәре Мэры яки Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктының 5 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

4.1 пунктта «Түбән Кама шәһәре Мэры» сүзләреннән соң «яки Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен өстәргә;

7.2 пунктта «аппаратның» сүзен «оештыру бүлегенең» сүзләренә алмаштырырга;

12.2 пунктта «ун көн» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин